**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

унберенче утырыш
**КАРАРЫ**

30 нчы июнь 2021 ел **№ 62** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2008 елның 22 августындагы 139/1 номерлы «Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәтнең төп принципларын Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнарның муниципаль хезмәткә бертигез керүе өлешендә гамәлгә ашыру максатларында,«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Уставы нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1.Теләче муниципаль районы Советының 2008 елның 22 августындагы 139/1 номерлы карары (Теләче муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 112 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 14 пунктына үзгәреш кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«14. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә тапшыра:

а) әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә форма буенча конкурс комиссиясе рәисе исеменә шәхси гариза;

б) фотография кушымтасы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

в) паспорт күчермәсе яисә аны алмаштыручы документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

г) кирәкле һөнәри белем, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар:

- хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (эш (хезмәт) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш), эш (хезмәт) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган яисә гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

- белем һәм квалификация турындагы документларның, гыйльми дәрәҗә бирү турындагы документларның, гыйльми исем бирү турындагы документларның нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләр;

д) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яки аны узуга комачаулаучы авыру булмавы турында документ;

е) гамәлдәге законнарда каралган башка документлар.».

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә китерелгән кушымтага, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы

Н.Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс конкурс үткәрү буенча комиссия рәисенә

ГАРИЗА

Мин,

________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашырга телим

________________________________________________________________

________________________________________________________________.

(вазифаның исеме)

Моның белән, үземнең Россия Федерациясе гражданины булуымны, (чит ил гражданы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданнары муниципаль хезмәттә булырга хокуклы), хокукка сәләтле булуымны раслыйм, Россия Федерациясе Дәүләт телен беләм һәм муниципаль хезмәт турында әлеге вакантлы вазыйфага карата гамәлдәге законнарда билгеләнгән квалификация таләпләренә туры киләм.

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы кодексы, Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 04 апрелендәге 199 номерлы карары белән расланган Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә белән таныштым.

Әлеге конкурста катнашу өчен минем тарафтан бирелгән документлардагы мәгълүматлар чынбарлыкка туры килә, ә документлар үзләре ялган түгел.

Конкурс комиссиясенә тапшырылучы белешмәләрне тикшерүгә каршы каршылыкларым юк.

Минем шәхси мәгълүматларны куллануга ризалык бирәм.

Гаризага түбәндәге документларны терким:

1) үз кулым белән тутырылган анкета;

2) 2 фоторәсем, зурлыгы 4 х 6;

3) паспорт күчермәсе һәм төп нөсхәсе яки аны алмаштыручы документ;

4) белем турындагы документның күчермәсе һәм төп нөсхәсе, шулай ук теләге буенча – өстәмә һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә бирү турында, гыйльми исем бирү турында;

5) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яки эш (хезмәт) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

6) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыруларның булмавы турында медицина учреждениесе бәяләмәсе;

7) гамәлдәге законнарда каралган башка документлар.

______________________ ______________________

(дата) (имза)